БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«__25_» __12__ 2019 г.

**КАРАР**
№ _386_

**«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 27 сентяберендәге 203 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә (алга таба – Тәртип) яңа редакциядә бәян итеп түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2019 елның 25 декаберенең 386 нчы
номерлы карары белән расланган

**Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен билгеләү һәм түләү механизмын билгели (алга таба - компенсация).

1.2. Компенсация гаиләсенең уртача кереме 20 000 сумнан артмаган, мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүгә компенсация алучы ата - анага (законлы вәкилгә) «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (алга таба-мөрәҗәгать итүче) белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә һәм түләнә.

1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә һәм Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр керткәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү Тәртибен раслау хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карарында билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

1.4. Компенсация күләме формула буенча исәпләнә:

**ДК = Ф х (100 % - МДД) - К, биредә:**

ДК-компенсация күләме;

Ф- тиешле елга башкарма комитет карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына баланы караган һәм тәрбияләгән өчен фактта алына торган ата-ана түләве күләме;

МДД - мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарның мөмкин булган чыгымнарының таблицага туры китереп билгеләнә торган максималь рөхсәт ителгән өлеше;

К-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

Таблица

**Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарның мөмкин булган чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше**

| Гаиләнең бер әгъзасына керем күләме | Ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага һәм аннан соңгы балаларга |
| мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменә кадәр (18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләр өчен) | 0 | 0 | 0 |
| 10000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10001 сумнан 15000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15001 сумнан 20000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |

1.5. Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарның мөмкин булган чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлешен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алына:

тәрбиядә булган һәм 18 яшькә җитмәгән балалар, шул исәптән хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәваланудa булган балалар, шулай ук матди карап тору өчен ата-аналар өлешчә түләү кертә торган интернат мәктәпләрдәге балалар;

18-23 яшьлек балалар (никахта тормаучылар), көндезге бүлектә белем алучылар, шул исәптән дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә, ата-аналар белән уртак яшәү фактына бәйсез рәвештә белем алучылар;

башка ата-ана гаиләсендә исәпкә алынмаган очракта, үги малайлар һәм үги кызлар;

гражданнар гаиләләрендә опекада торучы балалар;

тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.6. Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарның мөмкин булган чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлешен билгеләгәндә гаилә составында түбәндә саналган балалар исәпкә алынмый:

ата-анасы (тулы булмаган гаиләдә - ата-ананың берсе) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар;

тулы дәүләт тәэминатында торучы оешмалар.

## II. Компенсацияне билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча (булу урыны, тору урыны буенча мөрәҗәгать итүченең теркәлүе булмаган очракта) Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәгенең бүлекчәсенә, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар - тиешле мәгариф оешмасының теркәлү урыны буенча (алга таба – Үзәк бүлеге) түбәндәге документларны тапшыра:

банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп

(банк яисә башка кредит оешмасы аша компенсация алганда), әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча компенсация билгеләү турында гаризаны (алга таба - гариза);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган, компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен документларны (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы белешмәләрдән тыш);

баланың (балаларның) туу турында таныклык күчермәсен - баланың (балаларның) туу акты дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасыннан читтә алынган очракта;

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасыннан, һөнәри белем бирү оешмасыннан һәм югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан уналты яшьтән унсигез яшькә кадәрге баланы (балаларны) укытуны раслый торган белешмәне;

никахлашу турындагы таныклыкның күчермәсен - никахлашу дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасыннан читтә алынган очракта;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышаныч кәгазен;

компенсация алучының гаилә әгъзаларыннан яки законлы вәкилләреннән, түбәндәгеләрне раслый торган документ (документлар) (ирекле формада):

шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә рөхсәт булуын;

гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын органга яки оешмага тапшырганда аларның исеменнән эш итәргә вәкаләтләрен.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документны күрсәтә.

2.2. Үзәкнең бүлеге ведомствоара гарызнамәләр (запрослар) нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон рәвештә, компенсация билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне - бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта;

никахлашуны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне - никахлашуны дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасы территориясендә алган очракта;

опека (попечительлек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру турында, баланы матди карап торуга опекун (попечитель) тарафыннан алына торган акчаларның күләме һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында белешмәләрне;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында белешмәләрне;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматларны;

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенчаһөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм күләме, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр, шулай ук 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында түләүләр турында белешмәләрне;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсацион түләүләр һәм пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү күләмнәре турында белешмәләр;

Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләрне;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары яки социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала табу буенча пособие

күләме турында белешмәләрне;

вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособие күләме турында белешмәләрне;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары яисә социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә (учетка) баскан хатын-кызларга бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында белешмәләрне;

социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган бала тәрбияләгән өчен айлык пособие күләме турында белешмәләрне;

социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләр күләмнәре турында белешмәләрне;

әгәр медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы килеп чыгу нәтиҗәсе аның һөнәри хезмәткә яраклылыгын югалту булса, иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган яисә, иминият очрагы килеп чыгу нәтиҗәсе иминиятләштерелгән затның үлеме булса, аларны алуга хокукы булган затларга түләнә торган бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләренең күләме турында белешмәләрне;

мөрәҗәгать итүче белән бергә даими яшәү урыны (вакытлыча булу) буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләрне;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында уналты яшьтән алып унсигез яшькә кадәрге баланың (балаларны) белем алуы турында белешмәләрне;

гариза бирүченең паспортының чынлыгын раслау турында белешмәләрне - Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша мөрәҗәгать иткәндә.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативасы белән Үзәк бүлекчәсенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.

2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булса, компенсация билгеләү, Россия Федерациясе Пенсия фондында компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айның соңгы алты аенда булган гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр нигезендә башкарыла.

2.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнгә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр тапшыру бурычыннан азат ителә.

2.5. Әгәр мөрәҗәгать итүче торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия алучы гаиләсенә йә балага айлык пособие алучы гаилә составына керсә, аның гаризасы буенча билгеләнгән компенсация, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларны яисә балага айлык пособиене исәпкә алып, күрсәтелгән түләүләрне алу чорына яңадан билгеләнергә мөмкин.

2.6. Үзәкнең бүлегендә әлеге Тәртипнең 2.1 пунктының сигезенче абзацында күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән белешмәләр булганда, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү көненә кадәрге алты ай эчендә алынган булса, алар компенсация билгеләгәндә кулланыла.

2.7. Үзәк бүлеге гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән җиткерә (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр җибәреп, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша).

2.8. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә

һәм алты ай дәвамында түләнә.

2.9. Үзәкнең бүлегендә гариза бирүченең компенсация алу хокукын раслый торган мәгълүматлар булганда, компенсация гражданин мөрәҗәгать итмичә генә автомат рәвештә яңа срокка билгеләнә.

2.10. Компенсацияне билгеләүдән баш тарту өчен, булган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган, аны алуга хокук булмау нигез булып тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган гариза һәм документларның күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Компенсация алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган гаризалар һәм документлар (белешмәләр) электрон имза белән Россия Федерациясе законнары нигезендә имзалана һәм электрон чыганаклардан һәм (яисә) гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Интернет» челтәрен дә кертеп, файдаланып тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затларның, туу турында таныклыклары Татарстан Республикасыннан читтә бирелгән балалары булган гариза бирүчеләрнең, барлык балаларының әтисе (әнисе) белән бергә булмаган һәм ялгыз ана булмаган мөрәҗәгать итүчеләрнең, Татарстан Республикасы территориясеннән читтә өйләнешкән гариза бирүчеләрнең, мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләре булмаган керемнәре (вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча һәм Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондында яисә халыкны социаль яклау бүлегендә булган аналарга бәйле түләүләрдән; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре аша алына торган пособиеләрдән; шәхси ярдәмче хуҗалык алып барудан керемнәрдән тыш) булган мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризаларыннан тыш, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша җибәрә ала.

3.3. Үзәкнең бүлекчәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның чынлыгына һәм дөреслегенә шик туган очракта бирелгән вәкаләтләре кысаларында өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләргә өстәмә тикшерү үткәрелгән очракта, компенсацияне билгеләү турында яисә билгеләүдән баш тарту турында соңгы җавап мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән тикшерүне уздырганнан соң, ләкин ул Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткәннән 30 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә.

Сәламәтлек хәле, яше, җәяү йөри алмавы яисә транспорт белән тәэмин ителмәве аркасында банк счетын ачуга һәм аннан файдалануга мөмкинлеге булмаган гариза бирүчегә, компенсацияне түләү (илтеп җиткерү) элемтә оешмалары аша яисә әлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзегән акчалата түләүләрне илтеп тапшыруны гамәлгә ашыручы башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.5. Банк счетларына компенсацияне күчерү һәм элемтә оешмалары аша яисә әлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзегән акчалата түләүләрне илтеп тапшыруны гамәлгә ашыручы башка оешмалар аша илтеп тапшыру исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

3.6. Гражданнар билгеләнгән (билгеләнә торган) компенсация түләүне туктатуга китерә торган хәлләр (белем бирү оешмасын алмаштыру, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яисә ата-ана хокукларын чикләү, мөрәҗәгать итүченең һәм/яисә компенсация бирелә торган

баланың үлеме) барлыкка килү турында Үзәкнең бүлегенә мондый хәлләр килеп чыгу вакытыннан бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Түләүне туктатуга китерә торган шартлар килеп туганда, түләү тиешле шартлар туган айдан соң килүче айдан туктатыла.

3.8. Компенсация алучыларга хокуксыз түләнгән компенсация суммасы, шул исәптән дөрес булмаган белешмәләр белән документлар тапшыру, күрсәтелгән түләүне билгеләү хокукына йогынты ясый торган белешмәләрнең яшерелүе, хисап хатасы, Үзәкнең казначылык счетына яисә компенсациянең булачак суммалары исәбеннән кертү юлы белән компенсация алучылар тарафыннан тулы күләмдә түләнергә тиеш, ә мөрәҗәгать итүче түләүдән баш тарткан очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттелергә тиеш.

3.9. Компенсация алучыга Үзәк бүлеге гаебе белән тиешле һәм вакытында түләнмәгән компенсация суммасы узган вакыт эчендә нинди дә булса срокны чикләмичә түләнә.

3.10. Компенсация алучыга исән чакта түләнмәгән компенсация суммасы мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас булып кала.

3.11. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУнең
_________________________________________
муниципаль районындагы (шәһәр округындагы)
______ номерлы бүлегенә

______ номерлы ГАРИЗА
20__ елның ________

Мин, ______________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:
_______________________________________________________________________________,
(индексын, телефонын, электрон почта адресын күрсәтеп мөрәҗәгать итүченең почта адресы)
________________________________________________________________________________
(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары)
нигезендә эш итәм,
Снилс (компенсация алучының) __________
Түбәндәге адрес буенча яшәүче:
____________________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәтләрен алучының почта индексы, яшәү урыны буенча теркәү адресы)
____________________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте алучының шәхесен раслаучы документ реквизитлары)
____________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәтләрен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре билгеләвегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тәкъдим итәм:

| № | Документлар исеме | Нөсхәләр (экземплярлар) саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләү алучының гаилә составы:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне) | Кардәшлек мөнәсәбәтләре | Паспорт (балаларның туу турында таныклыклары) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Гаризада күрсәтелгән балалар (бала) тулысынча дәүләт тәэминатында тормый дип раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

______________________________________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукларында чикләнмәгән

_______ __________________________

(имза, гариза бирүченең имзасын расшифровкалау)

_________________________________________________________________

(бала өстеннән опека билгеләгәндә опека урнаштырган органның исемен һәм кайда булуын күрсәтергә)

Уналты яшьтән өлкәнрәк бала (балалар) белем ала:

____________________________________ __________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасының исеме)

____________________________________ ___________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасының исеме)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет реквизитлары _____________________________________________________

(банкта яисә башка кредит учреждениесендә законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәтен алучы яки аның законлы вәкиле тарафыннан ачылган шәхси счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге реквизитлары __________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының яисә аның законлы вәкиленең почта бүлекчәсе реквизитлары күрсәтелә)

Бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның дөреслеге өчен җавап тотам ______________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүмат, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, алуга риза:

почта адресы буенча язма рәвештә

телефонга смс-хәбәр җибәрү ______________________

(телефон номеры)

электрон документ рәвешендә

электрон почта адресы буенча ____________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы

дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша ________________________
(гариза бирүченең имзасы)

Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Пенсия фондында социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айдан соңгы 6 айда булган эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан минем файдага саналган түләүләр һәм башка түләүләр суммасы турындагы белешмәләр нигезендә яңа срокка автомат билгеләү белән килешәм.
____________________________________
(гариза бирүченең имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде __________ ___________ _______________________
(дата имза кую, белгечнең имзасын расшифровкалау)

Өзеп алу линиясе

Расписка-хәбәрнамә

Гариза бирүченең теркәлү номеры ______________
Документлар саны ______ берәмлек _____ биттә
Документларны кабул итте___________ __________ ___________________________ __________
(вазыйфасы) (имза) (имзаны расшифровкалау) (дата)